| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

Мөэмин-Каратай

«17» июнь 2020 ел №13

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 16 декабрендәге 39 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Бюджетның керем өлеше артуга бәйле рәвештә:
1.1. КБК 926 202 45160 10 0000 150 буенча башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар 408574,62 сум 68 тиенне юнәлдерергә:
- 0102 бүлекчә буенча 21573 сум 71 тиенне 2020 елның 1 кварталы нәтиҗәләре буенча; ТАССР ның 100 еллыгына 42471 сум 71 тиенне;
- 0104 «Үзәк аппарат» бүлекчәсе буенча ТАССРның 100 еллыгына 42471 сум 71 тиенне канцелярия чыгымнарына;
- 0409 «Юл хуҗалыгы» бүлекчәсе буенча 344000 сум 00 тиенне Мөэмин-Каратай авылы юлларындагы чокырларга ремонт ясау өчен;

1.2. КБК 926 117 14030 10 0000 150 «Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары” буенча 86000 сум 00 тиенне юнәлдерергә:
- 0409 «Юл хуҗалыгы» бүлекчәсе буенча 86000 сум 00 тиенне Мөэмин-Каратай авылы юлларындагы чокырларга ремонт ясау өчен.

2. 2020 елга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесен тоту буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслауга төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен 286823 сум 84 тиен күләмендә расларга.

1. 2020 елга бюджетның төп характеристикаларын расларга:

1) "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 4215654 сум 62 тиен;
2) "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4215654 сум 62 тиен;
3) "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджеты дефицитын 0 сум 00 тиен итеп.

2. "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга:
- 2020 елга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә.
3. «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында 2020 елга керемнәр күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.
4. "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:
- 2020 елга әлеге Карарга 5нче кушымта нигезендә.
5. «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре,максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бүлүне расларга:
- 2020 елга әлеге Карарга 6нчы кушымта нигезендә.

6. Әлеге карарны Мөкмин-Каратай авылы, Механизаторлар урамы, 31Б йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

"Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Ә.А.Ханнанова